БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» 11 2020 ел № 327

«2021 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 12 декабрендәге 543 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елга кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасы тарафыннан түбәндәгеләр белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән;

әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 19.11
327 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 92851 |
| | авыл җирлеге | 94213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 139227 |
| | авыл җирлеге | 143701 |